| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**07.02.2018** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 270** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайнар су белән тәэмин итү ихтыяҗлары өчен суны җылыту өчен кирәкле җылылык энергиясе күләме турында»2016 елның 30 мартындагы 726 номерлы карарын гамәлдән чыгару хакында

Монополиягә каршы Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 05-174/2017 номерлы эше буенча 1 нче күрсәтмәсе, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайнар су белән тәэмин итү ихтыяҗлары өчен суны җылыту өчен кирәкле җылылык энергиясе күләме турында»2016 елның 30 мартындагы 726 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин